ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«26 » декабрь 2020 ел** **№ 8**

**«Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кишет авыл җирлеге советының 31 октябрь 2019ел, №38 карары, 02 ноябрь 2020 ел, №1, 04 ноябрь 2020 ел, №3, 04 ноябрь 2020 ел, №4 , 25 декабрь 2020 ел, №5 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.« Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты; ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитетының 30 декабрь 2019 ел, №101 « Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл
җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИШИТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Яңа Кишет авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 26
декабрь 2020 ел, №8
карарына
1 нче кушымта

**« Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип « Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2021 елның 21 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а)көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы белән хәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар « Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, « Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңа Кишет авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 26
декабрь 2020 ел, №8
карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
« Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________________
_
______________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
____________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № _______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК _________________ОКАТО __________________
Түләү билгеләнеше
_______________________________________________________________________
__бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

« Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.___________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел
_____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*